وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә
Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз!
Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп,
төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№10 (107). 21 октябрь 2011 / 24-зөлкагъдә-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Фән динне өйрәнә, ә дингә фән кирәкме? ▹2◃



Фәйзелхак ИСЛАЕВ: "Кешене диненнән яздыру - зур гөнаһ" ▹3◃



Мөфти АКШның Дәүләт сәркатибе ярдәмчесе белән очрашты ▹4◃

## РЕКЛАМА КОЛЫ БУЛМЫЙК!

**23 октябрь – Россиядә реклама белән шөгыльләнүчеләр көне. Беренчедән, әлеге һөнәр ияләреннән башка дөньяны күз алдына да китереп булмыйдыр кебек. Чөнки кеше акылына массакүләм мәгълүмат чаралары белән тәэсир итү сәүдә, хезмәт өлкәләрендә генә түгел, сәясәттә, җәмгыятьтә билгеле бер идеологияне пропагандалау өчен дә кулланыла. Рекламаның төп вазыйфасы – сатуны арттыруга стимул бирү булса да, минем әлеге рекламаның башка якларына да тукталып үтәсем килә. Монда сүз гөнаһ, язык, тыелган эшләрне тарату турында бара. Рекламаларның илле процентган артыгы нәкъ менә шундый вазыйфаны үти. Кызганыч, бүгенге көндә реклама товарның үсеш-сатылуына гына түгел, җәмгыятебездә фәхешлек, бозыклыкны үстерүгә дә зур йогынты ясый.**

Мондый рекламаның эшчәнлек принцибы гади. Кешене алдап-йолдап, яңа товар алырга этәрәләр. Күп кенә кеше үз теләкләре белән идарә итә алмый һәм шул яңа товарны алу юлына бара да инде. Бу адымга аларның шәхси теләкләре, үз-үзләрен җиңә алмый торган сыйфатлары тарта.

Мисал өчен, сагыз рекламасы, беренче карашка, гади генә тоелса да, башка җенес вәкиле белән якынлыкка китерә ала дип күрсәтелә. Яки ир-атлар өчен чыгарыла торган ислемай рекламасын гына алыйк. Ул да бит, асылда, үзенең исе белән кызларны җәлеп итә һәм аларда дәрт уята. Бер генә сүз белән әйткәндә, реклама әхлаксызлыкны пропагандалый, аны уңышка һәм бәхеткә ирешү элементы буларак карый, кешене үз теләкләре колы итеп тәрбияли. Яки, мәсәлән, кешеләр арасында шундый фикер дә киң җәелде – хәзерге заман кешесе үзенең җәмгыятьтәге статусына тиң булган фатирга һәм машинага ия булырга тиеш. Шулай ук ул аларны гел алыштырып торырга, чөнки анысы да модага туры килеп торырга тиеш, имеш. Шул рәвешле, кеше кулланучыга гына әйләнеп бара. Хәзерге җәмгыятькә хас булган система түбән дәрәҗәдә булган теләкләрне канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән. Моннан тыш, күп кенә нәрсәләр культ дәрәҗәсенә әйләнгән. Һәм бу уңышка ирешү үрнәге булып санала.

Фарыз гамәлләрне үтәмәгән этник мөселманнар еш кына дин кешегә нинди-дер йөкләмә өсти дип уйлыйлар. Имеш, болай да ыгы-зыгылы, вакыт тыгыз заманда үз өстебезгә нигә тагы артык йөкләмә алырга? Алар фикеренчә, дин аларның тормышын чикли, вакытларын ала, әйтерсең лә, намаз укымыйча алар барысына да өлгерә алачаклар.

Бу кешеләр нык ялгыша. Бары тик дин һәм Аллаһы Тәгаләгә ышаныч аркылы гына кеше тулысынча азат була ала. Намазын калдырмаучы мөэмин-мөселман һәркөн үзенең кечкенәме-зурмы гөнаһлары өчен ярлыкау сорый, һәр гамәлен уйлап, нәтиҗәсе оялырлык булмаслык итеп башкара. Һәм аны реклама тозагына бирелдертеп, бозыклыкка бастырып булмый. Иманлы, дин тоткан кеше тормышта үз юлын билгели ала. Шуңа да ул реклама ымсындыруыннан, кызыктыргыч кредитлардан һәм башка төрле буш ымсындыргычлардан ерак тора. Иманлы кеше беркайчан да үз теләкләренең колы булмас.

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

## КАЗАНДА ВАКФ ҮЗӘГЕ АЧЫЛДЫ

**17 октябрьдә ТР мөселманнары Диния нәзарәте карамагында булган, Казан шәһәренең Тукай урамында урнашкан 3 нче йортта вакф үзәге ачылды.**



dumrt.ru

Вакф милке саналган бу бинаны төзекләндерү эшләре 1999 елда башланган. Тарихи архитектура һәйкәле архивларда сакланган эскиз-сызымнар ярдәмендә торгызылган. 2011 елга кадәр тотрыклы финанслау булмау сәбәпле эш авыр бара, төзелешне бары тик быел мөфтияткә яңа җитәкчелек килгәч кенә төгәлләү мөмкин була.

Бина ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт Фәиз җитәкчелегендә ачылды, дога кылынды. Әлеге күп профильле вакф үзәге ачылышында шулай ук ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге башлыгы Ирек Арсланов, Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифен үстерү фондыннан Александр Комадей һ.б. катнашты.

Тукайның тууына 125 ел тулу билгеләп үтелгән елда әлеге Тукай урамындагы бинаның яңадан торгызылып вакфка тапшырылуы күренекле бер вакыйга булды.

Исегезгә төшерәбез: әлеге ике катлы кирпеч йорт 1867 елда (Усманов мәчете белән бер үк вакытта) сәүдәгәр Җ.Б.Усманов тарафыннан төзетелгән булган һәм анда "Усмания" мәдрәсәсе урнашкан. Әлеге мәдрәсәдә татар әдәбияты классигы Г.Камал китап-белем дөньясына кергән, фикерен ныгыткан. 1910 елда биредә Г.Баруди шәкертләре дә дәресләр биргән.

***Нияз САБИРҖАНОВ***

## Рафикъ хәзрәт МИҢНӘХМӘТОВ:

# "Иң авырткан җиребез кадрлар мәсьәләсе"



**Без Әлмәт мөхтәсибе белән соңгы вакытта эшләнгән эшләр һәм киләчәккә булган планнар турында сөйләштек.**

*– Сезнең Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт районы имам-мөхтәсибе вазифаларына керешүегезгә дә берничә ай вакыт үтеп киткән. Кыскача гына әйтеп китә алмассызмы икән, шул чор эчендә нинди үзгәрешләр булды, нинди карар-нәтиҗәләр кабул ителде? Үз алдыгызга куйган максат-планнарга ни дәрәҗәдә ирешә алдыгыз?*

– Төп максатларның берсе – шушы мөхтәсибәттәге мәхәлләләр һәм мәдрәсәләр эшчәнлеген устав буенча алып баруны җайга салу. "Устав буенча" дигәндә, фикъһи һәм игътикади мәсьәләләрдә хәнәфи мәзһәбенә муафыйк рәвештә уку-укыту эшен алып бару һәм шулай ук мәчет-мәхәлләләрдә шушы тәртиптә эшне оештыруны күздә тотабыз. Төп эшләр әлеге мәсьәләләр буенча башкарылды. Ай саен диярлек мөхтәсибәт җыелышлары узды, шулай ук мәдрәсә укытучылары, администрация һәм көч структуралары вәкилләре белән дә әлеге юнәлештә аңлату эшләре алып барылды. Хәзерге вакытта мәдрәсәдә, Җәмигъ мәчеттә (биредә мөхтәсибәт урнашкан) һәм күпчелек мәхәлләләрдә дини мәрасимнәрне алып бару, мәчеттә җәмәгать намазлары уку, җомга алып бару, намаз вакытларына кагылышлы әйберләр булсын – бөтенесе дә бер тәртипкә салынып килә. Әлеге тәртипләрне хәзер имамнар таный. Дөрес, башта хәнәфи мәзһәбенә каршы чыгу очраклары да күзәтелгәләде. Хәзерге вакытта бөтен эшне дә устав һәм хәнәфи мәзһәбе буенча алып барабыз. Безнең көннәрдә хакимияттә дә әлеге мәсьәләләрдә бер төрле караш булырга тиеш икәнлекне аңладылар һәм шул рәвештә бергәләшеп эш алып бара башладык. Әлмәт мөхтәсибе буларак шунысын да әйтеп үтәсем килә: хәзерге вакытта имамнар белән ызгышлар, теге яки бу мәсьәләгә бәйле булган каршылыклар юк. Шулай ук кайбер мәсьәләләр: Болгарга бару, мәчетләрдә Коръән уку, Коръән уку мәҗлесләренә барулар тәртипкә салынып килә, аңлатыла һәм инде мондый эшләрдә дә мөхтәсибәт имамнары да, мәхәлләләр дә катнаша. Рәсми имамнар тарафыннан ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең фәрман-сәясәтенә каршы чыгучылар юк. Ягъни, бергәлектә – мөфтиятнең сәясәте белән мәхәлләләрнең сәясәте тәңгәл килеп бара, бердәмлек күренә. Бу, әлбәттә – зур уңыш. Дини юнәлеш, дини сәясәт мәсьәләсендә мәчетләр, мәхәлләләр – һәммәсе дә эшчәнлекләрен бер юнәлештә алып бара. Ә вактөяк проблемалар – ул һәр җирдә дә бар, шушы үзгәреш, элеккегедән аермалы буларак, шатландыра. Тагын бүтән куанырлык яңалыкларыбыз да җитәрлек: мин эшкә килгәч, бер яңа мәчет ачылды, хәзер яңа устав нигезендә өч мәхәллә теркәлү узып килә. Аннан соң Әлмәт шәһәрендәге 8 нче колониядә һәр сишәмбе көнне дәресләр үткәрәбез һәм анда шулай ук иҗтимагый комиссия дә төзелгән (анда суд та, хакимият вәкилләре дә катнаша). Без дә әлеге комиссия эшендә, ягъни тоткыннарны вакытыннан алда азат итү яки аларга булган шартларны җиңеләйтү гаризаларын карау комиссиясендә атна саен катнашабыз. Администрация канаты астында оештырылган шәһәр иҗтимагый шурасында айга бер мәртәбә катнашып киләм. Ул җыелыш формасында үтә, анда Ветераннар советы, Инвалидлар җәмгыяте кебек оешма вәкилләре һ.б. җыелып, шәһәргә кагылышлы мәсьәләләрне тикшерәләр, хакимият белән берлектә чишү юлларын эзлиләр. Шулай ук бездә наркотикларга каршы көрәш комитеты бар, мин аның эшчәнлегендә дә катнашам. Наркомания турында сүз барганда, шунысын да әйтеп китим: мәчетләребезгә Диния нәзарәте тарафыннан бирелгән вәгазьләрне тараттык, ул һәрбер мәхәлләләргә дә җиткерелде, җомга намазларында исерткечләргә һәм наркотикларга каршы бердәм хөтбәләр сөйләнде. Шулай ук экстремизмга каршы айлык кысаларында мәдрәсә шәкертләренә ачык дәрес үткәрелде, шулай ук администрациядә журналистлар өчен матбугат очрашуы оештырылды. Анда башка дин әһелләре дә катнашты. Аннан соң сентябрь аенда республикабызның барлык районнарында да узган чарада – "Милләтләр кроссы – 2011"дә катнаштык. Әлеге кросста хакимият вәкилләре белән мин үзем дә бер "круг" чаптым. (Ул көнне шәкертләрне дә алып чыккан идем, алар белән тагын бер тапкыр йөгердем.) Шуннан соң Рамазан аенда Җәмигъ мәчеттә зурлап авыз ачу мәҗлесләре оештырылды, көн саен 120 кешелек ифтар оештырылды. Әлмәт сукырлар җәмгыяте белән эш алып бардык. Рамазан аенда сукырлар белән күрештек, аларның барысын да авыз ачу мәҗлесләренә чакырдык, кырык кешегә өстәл әзерләдек. Әлеге чара пансионатта узды. Анда мөселманнар гына түгел, башка диндә булганнар да бар иде. Инвалидларны да шатландырдык. Мөхтәсибәт тарафыннан моңа кадәр мондый чаралар үткәрелмәгән.

***(Ахыры 2 нче биттә.)***

## Мөхтәсибәт ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### АЗНАКАЙ

**- Район мәдәният йортында, мәчетләребездә 15 октябрьдә Хәтер көне үткәрдек, – дип уртаклашты Азнакай шәһәре һәм Азнакай районы имам-мөхтәсибе Ә.Якупов. – Шәһит киткән бабаларыбызны Коръән-Кәрим укып, вәгазьләр сөйләп искә алдык.**

**Азнакай мәчетендә балаларны җыеп дин дәресләре дә бирелә башлаган. Алар атнага ике көн укый. Соңгы ике җомга намазының берсендә наркомания, икенчесендә террорчылык афәтләре турында вәгазь сөйләнелгән.**

**Биредә гошер җыю да киң масштабта алып барыла: "Гошерне районыбызның балалар бакчаларына бирдек. Әлмәт мәдрәсәсенә сиксәнләп капчык бәрәңге төшердек. Чаллы мәдрәсәсенә йөз капчыклап җибәрдек", – диде Әмирҗан хәзрәт. Азнакай шәһәрендә ике йөз капчыклап бәрәңге-яшелчә фәкыйрьләргә таратылган. Бу атнадан Корбан бәйрәменә әзерлек эшләре башланып киткән.**

### АРЧА

Узган пәнҗешәмбедә Арча Җәмигъ мәчетендә 60 имам һәм абыстай, 30 укытучы катнашында мөхтәсибәт җыелышы узган. Көн тәртибе авыл мәчетләрендә башланып киткән уку-укыту турында фикер алышудан гыйбарәт булган. Исегезгә төшерәбез: хәзерге вакытта Арча районының кырыктан артык мәчетендә укулар дәвам итә. Җыелышның икенче өлешендә гошер сәдакасы җыю һәм тапшыру буенча нәтиҗә ясалган. Гошер, нигездә, Казандагы дини уку йортларына җибәрелгән. (Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәгә – ике, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә, Россия ислам университетына, "Ак өмет" пансионатына берешәр машина гошер сәдакасы китерелгән.) Халык егермедән артык тонна бәрәңге белән яшелчәне гошер сәдакасы итеп биргән. Бу эшне оештыруда актив катнашкан имамнар җыелышта бүләкләнгән. Алар – Мурале авылыннан Расип хәзрәт Нәбиуллин, Шушмабаштан Рөстәм хәзрәт Йосыпов, Шека авылыннан Тәвис хәзрәт Локманов, Хәсәншәехтән Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев, Ташкичүдән Рәдиф хәзрәт Галәветдинов, Түбән Атыдан Раил хәзрәт Гыйләҗев. Әлеге җыелышка тәҗрибә алу өчен Чүпрәле районы имам-мөхтәсибе Фәһим хәзрәт Әхмәтҗанов, Саба районы имам-мөхтәсибе Айнур хәзрәт Әхмәтов та килгән булган. Катнашучылар чәй эчеп таралышкан.

- Октябрь ахырында Арчада мәчет каршында дини белем бирүче мөгаллимнәрнең район киңәшмәсе узар, дип көтелә. Хәзерге вакытта якынча көне егерме җидесенә билгеләнгән әлеге чарага әзерлек эшләре бара. Биредә районның җитмешләп укытучысы тәҗрибә уртаклашачак. Шулай ук үрнәк дәрес карау да күздә тотыла. Әлеге очрашу Арча мәчетендә узачак, – дип хәбәр итте безгә Арча районы имам-мөхтәсибе Раил хәзрәт Гыйләҗев.

### ЮГАРЫ ОСЛАН

**19 октябрьдә Югары Ослан-нан 14 кешелек беренче төркем хаҗ сәфәренә кузгалды. Моңа кадәр ел саен районнан бер-ике кеше генә хаҗ кылган булган.**

**Югары Ослан Җәмигъ мәчетендә якшәмбе укулары оештырылган. Иртәнге сәгать тугыздан өйлә намазына кадәр балаларны Гали хәзрәт Җиһаншин, сәгать икедән соң олыларны Солтан хәзрәт Нәҗметдинов укыта.**

**Хаҗдан соң Бакчасарай авылында да дәресләр башланыр, дип көтелә.**

**Исегезгә төшерәбез: быел Югары Ослан районы имам-мөхтәсибе Гали хәзрәт Җиһаншин да хаҗ кылырга ниятли.**

# "Иң авырткан җиребез кадрлар мәсьәләсе"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

***– Хәзер мөфтияткә яңа җитәкчелек килгәннән соң Диния нәзарәтендә дә, мөхтәсибәтләрдә дә берничә бүлек (яшьләр белән эшләү, уку-укыту, дәгъват һәм матбугат бүлекләре) булдырылды. Сезнең мөхтәсибәттә әлеге бүлекләр бер-берсе белән нинди бәйләнештә эшли һәм алга таба эшләү өчен нинди чаралар, проектлар өстендә эш алып барыла?***

– Безнең иң авырткан җиребез – кадрлар мәсьәләсе. Шуңа күрә мөхтәсиб алышынганнан соң шушы сез санап үткән юнәлешләр буенча бергә кулга-кул тотынып эшләрлек кадрларыбыз булмау борчуга сала анысы. Хәзерге вакытта бу яктан актив эш алып барабыз, дип әйтә алмыйм. Шунысын да әйтеп узасым килә: быел Әлмәт яшьләре дә Казанда булып узган Мөселман яшьләре фестивалендә катнашты. Күп кенә эшләрне башлап җибәрү, яшьләрне җәлеп итү – акча-финанс мәсьәләләренә дә бәйле. Хезмәт хакы түләү мөмкинлегебез туса, бу эшләребез дә җайга салынып китәр, дип уйлыйм. Хәзер җылыту сезонына керәбез, финанс хәлебез авыр. Актив яшьләрне мөхтәсибәт эшенә җәлеп итү зур кыенлыклар белән бара әлегә. Хәзерге вакытта үз сайтыбызны булдыру, газета чыгару өстендә эш алып барабыз. Финанс мәсьәләләре белән тоткарлыкларны хәл итеп бетергәч, эшебез җайга салыныр, дип өметләнәм.

***– Мәчетләр турында сүз чыккан икән, рөхсәт итсәгез тагын бер соравымны биреп узыйм әле. Сезне районыгыздагы мәчетләр саны канәгатьләндерәме, халыкка җитәрлекме алар? Киләчәктә яңа мәчетләр төзү планлаштырыламы? Әлмәт халкы мәчетләргә гыйлем алу, гыйбадәт кылу өчен күпләп йөриме?***

- Элек-электән Әлмәт нефтьчеләр төбәге буларак, кара алтын табучылар зур мәчетләр төзегәннәр. Бу – безнең шәһәрләргә дә, авылларга да хас төп сыйфат. Күпчелек авылларда шәһәрләргә генә хас зурлыктагы мәчетләр. Аны төзүен төзегәннәр, ләкин коммуналь хезмәтләрне ничек түләрбез, дип уйлап та карамаганнар. Күпчелек авыл мәчетләрендә бу проблема бар. Мин белгән биш-алты мәчетнең исә берешәр бүлмәсен генә җылыталар. Чөнки мәчетләр бик зур, ике катлылары да бар. Шуңа күрә җылылык өчен акча күп китә. Шунлыктан бер-ике бүлмәгә генә җылылык биреп, йөрүчеләр санынннан чыгып кына җылытмакчы булалар. Төп мәхәлләләрдә, авыл мәчетләрендә җомга намазына 15-20 кеше йөри. Кечкенә авылларда мәчетләр дә юк, имамнар да юк. Шулай булуга да карамастан, зур авыл мәчетләренең дә халык белән тулмаганнары бар. Җомгага биш кенә кеше йөргән мәчетләрне дә беләм. Шулай ук җомга укылмый торган мәчет-авыллар да бар. Ә Әлмәт шәһәренә килгәндә исә бездә тугыз мәчет, унбер мәхәллә эшли. Аларда җомга көнне мәчет тулган була. Җәмигъ мәчеттә исә җомгага 300-500 кеше йөри. Мактама посёлогында, Кәшер авылында икешәр мәчет эшли. Аларны икесендә дә җомгалар үткәрелә. Авылларга якшәмбе көнне барып, шәкертләр дәрес биреп кайталар. Рус авылы булган Акташта бүгенге көндә мәчет юк. Алар да мәчет салу артыннан йөри. Тагын шундый берничә авыл мәчет булдыру артыннан йөри.



***– Сезнең төбәк Ризаэддин Фәхреддин кебек зур шәхесләрне биргән як. Ишетүемчә, Сезнең Әлмәт мәдрәсәсенә үзегезнең районыкылар гына түгел, читтән дә килеп укучылар шактый икән. Хәзер сез эшне ничек оештырырга исәплисез: беренче чиратта, үзегезнең як кешеләренә дини белем бирүгә басым ясаячаксызмы, әллә бөтен республика, ил күләмендәге дини уку йорты булдырып, зур мәдрәсә булдыру өстендә эшләячәксезме? Сезгә нинди юл файда бирәчәк: үз төбәк кешеләрен генә укытып, аларны район авылларына эшкә җибәрүнең "плюс"лары күбрәк булмасмы?***

– Әлмәткә мин килгәнче үк, шәкертләрнең яртысы ук диярлек, дип әйтергә буладыр, Татарстаннан үзеннән түгел иде. Бу – берәүгә дә чит-ят әйбер түгел. Хакимият булсын, Диния нәзарәте тарафыннан булсын – хәзер республикабызның үз кешеләре күбрәк укысын, дигән караш бар. Әмма шулай булуга да карамастан, читтән килүчеләр дә (Ульяновск, Киров өлкәләреннән, Мордовия республикасыннан һ.б.) шактый. Без үзебезнең шәкертләрнең күбрәк булуын теләсәк тә, башка җирдәге мөселманнар Татарстанга төбәлгән, безгә ышанычлары зур. ТР – ул татарлар өчен милли үзәк кенә түгел, дини үзәк тә. Шуңа күрә чит төбәкләрдән киләләр, ләкин инде барыбер ныграк басым үзебезнең шәкертләрне тәрбияләргә булырга тиеш, дип саныйм. Чөнки, Әлмәтнең үзендә мәдрәсә булса да, анда йөздән артык егет-кыз укыса да, кайбер авылларга муллалар җитешми. Әлмәт районының берничә авылында гына да имамнар юк. Мәчетләр – бар, имамнар – юк. Мәчет ачылганда хәзрәт булган, хәзер инде ул бик олы яшьтә булу сәбәпле эшли алмыйм. Алар урынына алмаш юк. Бу проблеманы да мәдрәсә үзеннән үзе хәл итә алмый, без шул авыллардан урта буын вәкилләрен дә укыту ягын карарга тиешбез. Хакимият-дәүләт тарафыннан да үзебезнең шәкертләргә ярдәм итү юлларын эзлисе иде. Күпчелек шәкертләребез мул тормышта яши торган гаиләләрдән түгел, аларның күбесе нәрсәгә дә булса мохтаҗ. Аларга белем алу мөмкинлеге тудыру өчен, ярдәм итү зарур. Авыл Советлары тарафыннан да төрле ташламалар булдыру юлларын эзлисе иде. Болай эшләгәндә үзебезгә әзер кадрлар булыр иде, дип уйлыйм. Читтән никадәр генә кеше чакырып укытсак та, ул безнең кеше булмаячак, районыбызда имам булып хезмәт итәргә калмаячак. Хакыйкать шундый, моны һәртөрле тәҗрибәләр дә раслый. Әлмәт шәһәрендә ничә еллар мәдрәсә эшләп торып та, авылларда яшь имамнар юк. Аларның яхшырак укыганнары, өстәвенә, чит илгә укырга китү ягын эзли. Мондый яшьләрне бер яктан аңларга да мөмкин инде. Хезмәт хакы, торыр урыны булган җирләргә яшьләр бик теләп бара. Түләве булмаган, мәчеткә халык йөрми торган, хакимият тарафыннан ярдәм булмаган урыннарга атлыгып тормыйлар. Авылларның дини кадрлар проблемасын шул авыл белән генә хәл итеп була.

***– Сез Диния нәзарәтенең яңа җитәкчелеге белән ныклы элемтәдә торасыз. Мөфтиятнең нинди проектларын үзегезгә өлге итеп аласыз? Киләчәктә нәзарәт белән кулга-кул тотынышып нинди эшләр эшләргә ниятлисез? Республмикабызның башка мөхтәсибәтләре белән тәҗрибә уртаклашачаксызмы?***

– Иң мөһиме – дини юнәлешебезне бер тәртипкә алып килеп җиткезү. Диния нәзарәте үзенең ярдәмен һәрчак күрсәтеп тора. Хәзерге вакытта шушы урнашкан тәртипләрне ныгытып калдыру өчен яки эшне тагын да җәелдереп җибәрү өчен беренчедән, кадрлар мәсьәләсен, икенчедән, финанс мәсьәләләрен хәл итү зарур. Шуңа күрә дә Диния нәзарәте бу яктан ярдәмнәрен күрсәтергә вәгъдә итте. Якын арада сайтыбызны булдырып, газетабызны чыгара башлаячакбыз. Мондый үзгәрешләргә мин бик шат һәм җитәкчеләргә бик тә рәхмәтлемен. Бу – мөселманнарның бердәмлеге өчен дә бик файдалы. Шулай ук Россия ислам университетыннан да имамнар җибәрергә вәгъдә иттеләр. Эш-гамәлләребез нәтиҗәле булса иде, дигән теләктә калам.

**Әңгәмәдәш –**
**Нияз САБИРҖАНОВ**

# Фән динне өйрәнә, ә дингә фән кирәкме?

**Дини яңарыш фәннән аерылганга кыенлыклар кичерә. Шулай да башка конфессияләрдән үзгә буларак, ислам өчен дин һәм фән диалогы берникадәр җиңелрәк бирелә, дип саный тарихчылар.**



Чөнки белемле, мәгърифәтле булу ислам дине нигезенә салынган. Тарихчыларның дингә кагылышлы фәнни хезмәтләре, фикерләре белән 13 октябрь көнне Казан (Идел буе) федераль университетында уздырылган "Совет чорыннан соңгы вакытның рухи һәм сәяси культурасында традицияләр һәм яңалыклар: милли-дини мөнәсәбәтләр" дип аталган фәнни-гамәли конференциядә танышырга туры килде. Әлеге чараны КФУның Тарих институты Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә оештырды. Анда Россиянең утызлап төбәк-шәһәрләреннән галимнәр катнашты.

Конференцияне оештыручы профессор Ринат Нәбиев әйтүенә караганда, үзгәртеп кору елларында башланган дини үсеш фән эшлекләрендә зур кызыксыну уяткан тема. Чарада чыгыш ясау теләге белдергәннәрнең күплеге дә бу сүзләрне исбатлаучы бер дәлил.

Дин таралу никадәр киң колач ала барса да, галимнәр фикеренчә, дин һәм фән диалогы җиңел генә корылмый. Бер яктан гореф-гадәтләр, икенче тарафтан заман алып килгән яңалыклар килешүләрне җиңеләйтергә дә, шулай ук, киресенчә, катлауландырырга да мөмкин. Ничек кенә булмасын, шунысы ачык: бүгенге җәмгыятьтә дин таралу һәр өлкәгә тәэсир итә. Хәтта экологлар кешелекне коткарырга иң беренче чиратта дин әһелләрен чакыра. Бүген күпләр европача яшәргә, ягъни зур йортлы, ике машиналы булырга омтыла. Чынлыкта менә шул "европа" ихтыяҗын канәгатьләндерер өчен кешелеккә биш планета кирәк икән. Экологлар булганын җимергәнче кешеләрнең энергиясен рухи якка юнәлдерергә, шул рәвешле аларның матди кызыксынуларын киметергә өнди, дип сөйләде Ольга ханым Сенюткина.

Профессор Ольга Коршунова хәзерге заманда дини үсешнең өч төрле моделе барлыгына тукталды: Америка, Европа һәм Россия. Һәркайсында дин мәсьәләләре төрлечә хәл ителә һәм ул аерым үзенчәлелекләргә ия. Россия эченә керсә дә Татарстан дини мөнәсәбәтләр кору, үстерү буенча үзе аерым бер үрнәк булып тора. Ринат Нәбиев Татарстан үзенчәлеген барлап: "Узган гасырның туксанынчы елларында төрле диннәрнең кинәт таралуы шартларында православие һәм ислам дине арасында тигезлек булдыру максатыннан сәяси формула эшләнде. Барлык диннәрнең тигез хокуклы булуы сәяси күзәтү астына алынды", – диде.

Татарстан Фәннәр академиясе академигы Рафаэль Хәкимов бүгенге заман хәлләренә җавапны тарихтан барлау кирәклеккә һәм традицияләр мөһимлелегенә басым ясады. Ул: "Тормыш традицияләр белән бергә бара. Бүгенге көндә үткән заман 95, киләчәк 5 процент кына. Традицияләрне санламаганда һәм булган нәрсәне җимергәндә фанатизм, онытылганнарга әйләнеп кайту күзәтелә. Алга китеш юк. Теләсә кайсы яңарыш традицияләр кысаларында алып барылырга тиеш", – дигән сүзләрне әйтте.

Әлеге конференция күрсәткәнчә, бүгенге галимнәр дингә бәйле фәнни хезмәтләр язып кына калмый, алар хәтта бу хакта Россиякүләм сөйләшүләр уздырырга да әзер. Әлбәттә, үз "казаннарында" - үзләре арасында. Ә динчеләр фән белән кызыксынамы? Әлеге сорауга җавап рәвешендә, бәлки алга таба дин әһелләренең фәнни чаралары үткәрелә башлар әле... – дип яза Татарстан Республикасының intertat.ru электрон газетасы.

***Айзирәк ГӘРӘЕВА***

# Фәйзелхак ИСЛАЕВ:
# "КЕШЕНЕ ДИНЕННӘН ЯЗДЫРУ - ЗУР ГӨНАҺ"

## "ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ" ДОСЬЕСЫ



***Тулы исеме:*** *Фәйзелхак Габделхак улы Ислаев*

***Туган елы:*** *1946 елның 2 гыйнвары*

***Туган ягы:*** *Пермь өлкәсенең Октябрь районы Уразмәт авылы*

***Фәнни дәрәҗәсе (учёная степень):*** *тарих фәннәре докторы (2005)*

***Фәнни исеме (учёное звание):*** *өлкән укытучы (1983), доцент (1988), профессор (2007)*

***Хезмәт юлы:*** *Пермь дәүләт авыл хуҗалыгы институтының укытучы-доценты (1983-1993), гуманитар факультет деканы (1990-1992), Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты өлкән фәнни хезмәткәре (1993-1998), Татарстан мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм яңадан хәзерләү институтының тарих һәм җәмгыять белеме кафедрасы мөдире, профессоры (1998 елдан алып бүгенге көнгә кадәр), "Мәгариф" журналының редколлегия әгъзасы (2007 елдан).*

***Басылып чыккан хезмәтләре саны:*** *9 китап һәм ике йөзгә якын мәкалә.*

***Дөнья күргән кайбер китаплары:*** *"Джихад татарского народа" (1998), "Православные миссионеры в Поволжье" (1999), "Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: от конфронтации к терпимости" (2001), "Ислам и православие в России. XVIII век" (2004), "Батырша восстаниесе: 1755 ел" (рус (2004) һәм татар (2005) телләрендә), "Я и моя родословная" (2009) уку әсбабы.*

**– Сезнең 1999 елда Татарстан китап нәшриятында "Идел буенда православие миссионерлары" ("Православные миссионеры в Поволжье") дигән монографиягез дөнья күргән иде. Әлеге китапта сүз ниләр турында бара?**

– Патша Россиясе идеологиясендә дин, хөкүмәтнең басып алу сәясәтенә нигез буларак, мөһим урынны алып торган. Империядәге рус булмаган халыкларны рухи коллыкка төшерү хәрәкәте Пётр I заманында аеруча көчәя, беренче рус императоры үлгәннән соң, 1731 елда "Комиссия новокрещёнских дел", соңыннан "Новокрещёнская контора" төзү белән бу эшкә үзенә күрә бер йомгак ясала. XVIII гасыр уртасында бу контора Идел буе халыкларын һәм Россиянең башка төбәкләрендәге рус булмаган халыкларны көчләп чукындыруда төп рольне уйный. Әлеге теманы өйрәнеп, шушы монографияне бастырганчыга кадәр, бу миссионерлык оешмасының тарихы бик аз яктыртылган иде. Сәбәбе – Русия тарихындагы динара мөнәсәбәтләрне беркатлы, дәүләтне һәм православ чиркәвен иделлаштырып күрсәтү теләге. Бу патша заманына да, совет чорына да хас әйбер. Шуңа да карамастан, әлеге тема Россиядә актуальлеген аз гына да югалтмый. Тарихны белмәү халыклар арасындагы дуслык-татулык мөнәсәбәтләренә нигез була алмый.

**– Төгәлрәк итеп әйткәндә, әлеге хезмәттә нинди проблемалар тикшерелде?**

– Төрле чыганакларга нигезләнеп язылган бу хезмәттә әлеге "Новокрещёнская контора"ның утыз өч еллык (1731-1764) тарихы өйрәнелде. Мин игътибар үзәгенә татар һәм Идел буенда яшәүче башка халыкларны чукындыруның төрледән-төрле ысуллары, "инородцы" дип аталган халыкларның бу афәткә, рухи көчләүгә актив каршылык күрсәтүен алдым. Китапның аерым бүлекләре "Контора"ның мәгълүм идарәчеләренә (Дмитрий Сеченов, Сильвестр Гловацкий, Евгений Скаловский, Лука Канашевич – Аксак Каратун), Батыршаның баш күтәрүенә багышланды. Әлеге китап киң катлам укучыларга атап язылды, ул марилар, чувашлар, татарлар һәм руслар өчен дә кызыклы. Китап тарихыбыздагы билгесез күп нәрсәләрне аңларга ярдәм итәчәк.

**– Татар дөньясында күптәннән бер бәхәс бара: керәшен кардәшләр "без үзебез теләп чукындык, бу Явыз Иван заманына кадәр үк булган хәлләр", диләр. Сез әлеге мәсьәләдә нинди дә булса чор идеологиясе тәэсирен күрмисезме?**

– Идеология – ул шундый көчле корал ки, ул кеше аңына кереп урнаштымы, аннан котылу искиткеч авыр. Христиан миссионерлары "сезнең ата-бабаларыгыз православие динен бик күптән кабул иткән" дигән ялган фикерне керәшен кардәшләр аңына нык сеңдергәннәр, гәрчә моны раслаучы бер генә факт та юк. Мин әлеге чор идеологиясе мәсьәләләрен 2001 елда Казан дәүләт университеты нәшриятында дөнья күргән "Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: от конфронтации к терпимости" дигән аталган китабымда яктырттым. Кызыксынучылар өчен әлеге хезмәттәге бүлек исемнәрен дә санап узуны кирәк дип саныйм: "Ислам и православие в России в первой трети XVIII столетия", "Время новокрещёнской конторы", "Движение сопротивления против духовного насилия", "Религиозная политика государства во второй половине XVIII века".

**– XVIII йөз патшаларының, шул исәптән реформатор Пётр I шул чордагы милли һәм дини сәясәткә мөнәсәбәтләре ничек булган?**


– Беркемгә дә сер түгел: Явыз Иван һәм аннан соң тәхеттә утырган рус патшалары үзләренең төп дошманы, шул исәптән дин дошманы итеп татарларны санаган. Бу хакта шул заманның Европа тарихчылары гына түгел, прогрессив карашлы рус кешеләре дә язып калдырганнар. Шундыйларга профессорлар В.А.-Ключевскийны, С.М.Соловьёвны да кертергә була. Татарларны көчләп чукындыру эше Пётр I патшалык иткән заманда аеруча көчәя. Әле генә сез телгә алган китабымда моны тормышка ашыруның төрле формалары күрсәтелгән. Бу – морзаларның, йомышчы татарларның (служилые татары) җирләрен тартып алу, салым салу, православие динен кабул итүчеләрне армия хезмәтеннән азат итү; бүләкләр бирү, акча түләү һ.б. Пётр I дә, синод та "тимер куллар белән" мөселманнарны һәм мәҗүсиләрне чукынырга мәҗбүр иткәннәр.

**– Пётр I үлгәннән соң эшләр ничек бара?**

– Бу эш Пётр I үлгәч, патшабикә Анна Иоанновна, аның кызы Елизавета Петровна патшалык иткәндә дә тукталмый, шушы елларда Идел буенда яшәгән халыкларны күпләп чукындыру оештырыла. "Прәннек һәм чыбыркы" алымыннан тыш, агарту-аңлату эшләре дә киң җәелдерелә. Дөрес, моның нәтиҗәсе зур булмый, бигрәк тә сыйфаты ягыннан. Мәсәлән, Казан митрополиты Сильвестр болай яза: "Чукындырылган татарлар мөселман туганнары белән йөрешәләр, шуңа күрә чиркәүгә барырга вакытлары калмый. Мөселман сәүдәгәрләре православие динен кабул иткән татарларны үзләре белән товарга йөртә. Казанның Татар бистәсендә дүрт мәчет бар, алар да христианнарга кире йогынты ясый".

**– Патша властьлары белән синод бергә Идел буе мөселманнарын чукындыру өчен нинди алымнар уйлап таба?**

– Мисал өчен, 1731 елның 23 августында, синод указы нигезендә, Казан губернасындагы халыкларны чукындыру эше белән шөгыльләнәчәк комиссия



төзелә. Комиссиянең эш урыны итеп 1556 елда Успенский монастыре салынган Зөя (Свияжск) шәһәре сайлана. Соңыннанрак бу комиссияне "Новокрещёнская контора" дип атыйлар. Бу контора 1731-1764 елларда эшли һәм мөселманнар, мәҗүсиләр арасында иң яман эз калдырган дини оешма итеп хәтердә кала. Бу контора бик зур уңышларга ирешә. Башта, әлбәттә, православ динен кабул итүчеләр саны бик күп булмый. Мәсәлән, 1731 елда нибары 108 кеше чукындырыла, моның өчен аларга акча, кием-салым бирелә. 1732 елда христиан динен 201 кеше кабул итә. Әле генә чукындырылган кешеләр кире үз диннәренә кайтмасыннар өчен алар христианнар күпләп яши торган урыннарга күчереләләр. 1747 елда христиан динен кабул итүчеләр саны 107 меңнән артып китә. Бу искиткеч зур сан. Барлыгы шушы контора эшләгән елларда православ динен кабул итүчеләр саны 400 мең тирәсе, шулар арасында татарлар саны 12 меңнән артыграк.

**- Монографиянең өченче бүлегендә ("Движение сопротивления против духовного насилия") ниләр турында сүз бара?**

– Әлеге бүлек, югарыда әйтелгәнчә, көчләп чукындыруга каршы мәҗүсиләрнең (удмурт, мари, мордва, чуваш) генә түгел, мөселманнарның да баш күтәрүләренә багышланган. Миссионерларга каршы тору башка төбәкләрдә дә күзәтелә. Шулардан берничә мисал. 1747 елда Казандагы Татар бистәсе, Кама аръягындагы 17 авыл, көчләп чукындыруга, христиан динен кабул итүчеләр өчен өстәмә чамасыз артык салымнарга, лашманчылыкка каршы восстание әзерли башлый. Тик халык ризасызлыгын сизгән җирле администрация Татар бистәсенә, авылларга гаскәриләр урнаштырып восстаниене кичектерә алалар. Мөселманнар арасындагы көчле ризасызлык 1755 елгы Батырша мулла җитәкчелегендәге восстаниегә китерә. Восстаниенең үзәге – хәзерге Башкортстан республикасы һәм Пермь краеның көньяк районнарындагы татар һәм башкорт авыллары. Әлбәттә, мондый чыгышлар уңышлы тәмамланмый һәм моның объектив сәбәпләре бар. Шулай да алар эзсез генә үтми. Батырша восстаниесе нәтиҗәсендә өстәмә салымнар юкка чыгарыла, мәчетләр төзергә рөхсәт ителә, ә иң данлыклы миссионерлардан Лука Канашевич һәм Сильвестр Гловацкий эшләреннән алына. Моңа Пугачёв чуалышлары да өстәлә. Әби патша халыкны тынычландыру өчен кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр була. Мәсәлән, Уфада мөфтият оештырыла. 1783 елның 28 гыйнвар фәрманы белән Екатерина II татарларга үз арасыннан ахуннар сайларга рөхсәт итә. Лука Канашевич боерыгы белән бик күп мәчетләр җимерелсә, Екатерина II исә мәчетләр салырга рөхсәт бирә. Ә мөфтият бер генә мәчет тә булмаган Уфа шәһәрендә (1789 елның 4 декабрендә) ачыла. Әлбәттә, мондый ташламалар патшабикә мөселманнарга мәрхәмәтле булган, дип уйларга җирлек тудырмый. Шулай да Екатерина Икенчене татарлар Әби патша дип юкка гына атамаган. Шул уңайдан В.Ключевскийның: "Екатерина II вакытында хөкүмәтнең тырнаклары бүре тырнаклары булудан туктамады, әмма хөкүмәт халык тиресен кулның арт ягы белән сыйпый, ә беркатлы халык моны ананың яратып сыйпавы дип кабул итә", – дигән сүзләрен искә төшерү урынлы булыр.

**– Сез 2005 елда КДУда (хәзерге Казан (Идел буе) федераль университеты) "Россия дәүләтенең дини сәясәте һәм Идел-Урал төбәгендә аның тормышка ашырылуы (XVIII гасыр)" дип исемләнгән темага докторлык диссертациясе яклаган идегез.**

– Бу – совет заманында телгә алырга да ярамаган, мөселманнарны чукындыру мәсьәләләренә багышланган гыйльми хезмәт. Мин әлеге хезмәтемдә күп кенә чыганакларны беренче тапкыр әйләнешкә кертеп, дәүләт тарафыннан яклап килгән миссионерлык эшенең асылын ачтым. Тарих фәннәре докторы, профессор Индус Таһиров минем фәнни киңәшчем булды. Аңа һәм башка коллегаларга мин бик рәхмәтле, чөнки мондый хезмәтне диссертация итеп яклау өчен батырлык кына җитми, галимнәрнең уңай бәяләве дә бик мөһим.

**– Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт!**

*Әңгәмәдәш – Нияз САБИРҖАНОВ*

# Мөселман яшьләре тарихчы Фәйзелхак Ислаев белән очрашты



*ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе Айнур Солтанов һәм очрашу кунагы – тарихчы Фәйзелхак Ислаев*



*Очрашуга кырыктан артык кеше җыелды.*

***Кичә "Мин һәм минем шәҗәрәм" дип исемләнсә дә, тарихка, милли мәсьәләләргә кагылышлы сораулар да күтәрелде.***

## Яхшы генеалогия – бер машина бәясе

"Мин һәм минем шәҗәрәм" китабы авторы буларак, ул бу китапның язылу тарихы белән дә таныштырды: "Хәзер безнең нәсел шәҗәрәсе унбер буыннан тора. Әмма оныклар, балалар тарих белән кызыксынмый, нәсел турында да уйланмый. Сөйләп-сөйләп карыйм, алар: "Берни дә кирәкми", – дип җавап бирә. Шуннан соң укытучылар белән сөйләшә башладым, балалар белән эшләргә кирәк бит, дим. Алар: "Бездә китап юк", – диләр. Шуннан соң мин: "Ярый, булмаса язып бирәм мин сезгә китап", – дидем.

Ул шәҗәрә төзүдә үз киңәшләрен дә җиткерде:

– Архивка кермичә дә биш буынны табарга була, әти-әни, әби-бабаларыгыз бу эштә ярдәм итәр. Ә менә 6-7 буыныгызны эзләргә кирәк булса, "ЗАГС"ка мөрәҗәгать итегез. Ул бик кыйммәткә төшми. Интернет аша да архивларны табарга, электрон адрес белән мөрәҗәгать итәргә була. Аннары, халык санын алу кәгазьләреннән эзләргә мөмкин. Алар аша XVII гасырга кадәр булган мәгълүматны табарга мөмкин, - дип аңлатты Фәйзелхак әфәнде.

Яхшы генеалогия бер машина бәясе торырга мөмкин икән.

## Алтын Урданың чын исеме – Алтын Урта

Очрашуда Алтын Урда дәүләте турында да сүз чыкты. Фәйзелхак әфәнде: "Алтын Урданың беренчел исеме – Алтын Урта булган. Төрки бабаларыбыз, дөнья зур, ә уртада – Сарай, алтын тәхет, Алтын Урта дип күзаллаган.

(Ахыры 4 нче биттә.)

# Мөхтәсибәт ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### ӘЛМӘТ

Быел Әлмәт шәһәренең алты мәчетендә якшәмбе укулары башланган. "Элек исә мондый укулар кич белән генә узган. Хәзер Җәмигъ мәчеттә өч төркемгә (балалар, ир-атлар, хатын-кызлар) бүленеп дини укулар үтә", – диде Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт районы имам-мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтов. Моннан тыш, Әлмәт районының ун авыл мәчетендә дә дини дәресләр бара икән. Уку-укыту эшенә шәкертләр дә җәлеп ителгән. Районда дин әһелләре һәртөрле җыелышларда да актив катнаша, мисал өчен, узган чәршәмбе көнне Рафикъ хәзрәт спортны үстерүгә багышланган шәһәр күләмендәге җыелышта катнашкан. Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәт (ФСИН), аерым алганда, төрмәләр белән эшләүгә дә күп көч сарыф ителә, һәр сишәмбе көнне төрмәдә утыручыларга барып лекцияләр укыла.

Гошер сәдакасы җыю буенча да быел Әлмәт төбәге активлык күрсәтте. Барлыгы егерме ике авылдан яшелчә җыеп алынды һәм ул мәдрәсәләргә таратылды. Алай гына да түгел, күрше республика-өлкәләр дә гошер сәдакасы китергән. Пенза өлкәсеннән генә дә сигез тонна (!) кәбестә алып килгәннәр. Татарстан районнары исә Әлмәт мәдрәсәсенең бәрәңгегә булган ихтыяҗын канәгатьләндергән.

### БАУЛЫ

**"Быелдан район мәчетләрендә ким дигәндә икешәр төркемдә укулар башланып китте", – диде Баулы районы имам-мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Биккинин. Баулы шәһәренең "Өмет", "Гали" мәчетләрендә өлкәннәр өчен дини дәресләр үтә. Шәһәрнең "Шигаби" сәүдә үзәгендә намаз уку бүлмәсе бар икән. Әлеге бүлмәдә дә дәресләр оештырырга булганнар. Монда да дәресләр ике төркемгә бүлеп уздырыла. Атнасына ике тапкыр узучы дәресләрдә дүрт мөгаллим, ике имам-хатыйб укыта. Баулы районының Кызыл Яр авылы мәчетендә дә дәресләр оештырылган.**

### АЛАБУГА

- Шәһәр мәчетләрендә кышка әзерләнү буенча ремонт эшләре алып барыла, – дип башлады үз сүзен Алабуга шәһәре һәм Алабуга районы имам-мөхтәсибе Әҗмәл хәзрәт Саматов. – Моннан тыш, Алабугада ике яңа мәчет төзү эше дә киң колач белән бара. Берсенә – "Ихлас", икенчесе "Шатлык" дип исем бирдек. Мәчет төзелешенә район хакимияте зур ярдәм итә. Емельянов Геннадий Егоровичка зур рәхмәт белдерәсебез килә.

Алабуга Җәмигъ мәчетенә быел эшкә тәҗрибәле, белемле имам – Азат хәзрәт Шәрипов килгән. Ул мәчеттә укулар башлап җибәргән.

Шәһәрнең 31 нче балалар бакчасында мөселман балалары төркеме оештырылган һәм хәләл туклану булдырылган.

Күптән түгел генә мәчеткә йөрүчеләр өчен Болгар шәһәренә экскурсия оештырылган. 15 октябрьдә Хәтер көне билгеләп үтелгән. Җәмигъ мәчеттә атнаның дүрт көнендә дәрес-лекцияләр башланган.

### ЗӘЙ

**Зәйдә гошер сәдакасы җыю киң колач белән бара.**

**- Районыбызның ун мәхәлләсеннән гошер җыелды. Барлыгы сигез тоннадан артык яшелчә һәм бәрәңге китерделәр, – дип белдерде Зәй шәһәре һәм Зәй районы имам-мөхтәсибе Сәгыйть хәзрәт Камалов. – 17 октябрьдә өч тонна гошерне Чаллы шәһәрендә яңа ачылган пансионатка җибәрдек.**

**Зәй шәһәрендә биш мәхәллә бар. Җәмигъ мәчеттә ремонт эшләре башкарылган, идәннәре җылытылган. Финанс чыгымнарын район спонсорлары күтәргән. Түбән мәхәлләдә төзелеп килүче мәчеткә ай куелган. Әлеге мәчетне Нәсимә ханым Марханова төзетә. Хәзерге вакытта Түбән мәхәллә мәчетен бизәү һәм җылыту эшләре башкарыла. Икмәк кабул итү пункты мәхәлләсендә зур мәчет төзелеп килә, бүгенге көндә аның стенасы күтәрелә. Мәчетне "Трубастрой" оешмасы җитәкчесе Фоат Гарифов төзетә. Ә Мирный бистәсендә исә мәчет төзелешенә участок бүлеп бирелгән. Биредә төзеләчәк мәчеткә Фоат белән Гөлдәнинә Саматовлар гаиләсе иганәлек ярдәме күрсәтә.**

*Яңалыкларны Нияз САБИРҖАНОВ җыйды*

# ГАЛӘМНЕ ИШЕТӘСЕМ КИЛӘ!

***2007 елда туган Әхмәтҗанова Мәдинә Ленар кызының тумыштан колаклары ишетми. Инвалид кызның әле бер тапкыр да әти-әнисенең тавышын, кошлар сайравын, чишмә челтәрәвен ишетә алганы юк...***



Хәзерге вакытта Мәдинәгә операция ясатып, аның ишетү сәләтен кайтару мөмкинлеге бар. Бүгенге көндә операция өчен кирәк булган сумманың шактые җыелган, әмма шулай да йөз мең сум акча җитеп бетми.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге "NEY" фотостудиясе белән берлектә "Галәмне ишетәсем килә" дип исемләнгән хәйрия акциясе үткәрә. Фотосессиядән кергән барлык керемнәр дә Мәдинәгә операция ясату өчен тапшырылачак.

Мәдинәгә ярдәм итәргә теләсәгез, барыгызны да 22, 23 октябрь көннәрендә 12.00 сәгатьтә "Ленин бакчасы"нда көтеп калачакбыз. Фотосессия бәясе – 500 сум.

Үзегезне кызыксындырган барлык сораулар белән дә Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге мөдире Гөлнара Садыйковага мөрәҗәгать итә аласыз: +7 (843) 236-52-12 (эш), 89872639889.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): "Мөселман кардәшенең берәр төрле кыен мәсьәләсен чишәргә булышканнарга – гомере буе Аллаһы Тәгалә каршында гыйбадәттә булган кешегә язылган кадәр савап язылыр һәм Аллаһы Тәгалә аның 72 борчу-мәсьәләсен (иң кечкенәсе – Аның ярлыкавы) чишәр", дип вәгъдә иткән.

**DUMRT.RU**

# МӨСЕЛМАН БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН ИНТЕРНАТ АЧЫЛДЫ

***13 октябрь көнне Чаллы шәһәренең Крупская урамында урнашкан 14 нче йортта – "Әбүзәр" мәчете янында мөселман балалары өчен төзелгән интернат ачылу тантанасы булып узды.***

Интернат эшчәнлегенә килгәндә, ул күп балалы һәм аз керемле гаиләләр, 11-17 яшьлек яшүсмерләр, ялгыз ата-аналарга хәйрия ярдәме күрсәтү һәм сәләтле балаларга белем-тәрбия бирүдә булышлык итүне күздә тота. Балалар гомуми урта белем бирү мәктәпләрендә белем алса, интернатта исә алар традицион ислам кыйммәтләрен үзләштерә алачак.

Биредә алга таба Россия ислам университетына керергә теләүчеләр өчен әзерлек эше алып бару да күздә тотыла.

**DUMRT.RU**

nabchelny.ru



# Ноябрь аенда ничек ял итәчәкбез?

***РФ Хезмәт Кодексының 112 нче маддәсе нигезендә, узган елдагы кебек үк, 4 нче ноябрь – Халыклар бердәмлеге көне – ял көне булачак.***

"Татарстан Республикасында бәйрәм көннәре һәм истәлекле көннәр турында"гы ТР Законы нигезендә өстәмә бәйрәм көннәре билгеләнде. Болар: 6 ноябрь – ТР Конституциясе кабул ителгән көн һәм Корбан бәйрәме.

Ай календаре һәм традицияләр буенча Корбан бәйрәме башлануга туры килгән көн ТР Президенты Указы белән билгеләнә. Әлеге Закон нигезендә 2011 нче елның 1 нче августында кабул ителгән ТР Президенты Р.Н.Миңнехановның "Мөселман бәйрәмнәрен үткәрү турында"гы Указында 2011 нче елның 6 нчы ноябре – Корбан бәйрәме башлануга туры килә торган көн, дип билгеләнгән.



Быел 6 нчы ноябрь (эш көне булмаган бәйрәм көн) – ТР Конституциясе кабул ителгән көн һәм Корбан бәйрәме – ял көненә – якшәмбегә туры килде. РФ Хезмәт Кодексының югарыда күрсәтелгән маддәсе нигезендә, эш көне булмаган бәйрәм көне ял көненә туры килгән очракта, ял көне бәйрәмнән соң килә торган эш көненә күчерелә. Шунлыктан, 6 нчы ноябрьнең якшәмбе ялы дүшәмбегә – 7 нче ноябрьгә күчереләчәк.

Шулай итеп, быел Татарстанда 4 нче һәм 7 нче ноябрь көннәре эш көне булмаган бәйрәм көннәре, ә 7 нче ноябрь – ял көне булып саналачак, дип хәбәр итә tatar-inform.ru сайты.

ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгыннан хәбәр итүләренә караганда, 5 ноябрь – шимбә көн - алты көнлек эш графигы нигезендә эшләүчеләр өчен эш көне булачак. Әлеге көн – бәйрәм алды көне, шуңа күрә эш сәгате бер сәгатькә кыскартылачак.

***Нияз САБИРҖАНОВ***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 22.10.2011 | 05:59 | 07:27 | 13:02 | 15:32 | 17:27 | 18:55 |
| Якшәмбе | 23.10.2011 | 06:01 | 07:29 | 13:02 | 15:30 | 17:25 | 18:53 |
| Дүшәмбе | 24.10.2011 | 06:03 | 07:31 | 13:02 | 15:28 | 17:22 | 18:51 |
| Сишәмбе | 25.10.2011 | 06:05 | 07:33 | 13:02 | 15:26 | 17:20 | 18:49 |
| Чәршәмбе | 26.10.2011 | 06:07 | 07:35 | 13:02 | 15:24 | 17:18 | 18:46 |
| Пәнҗешәмбе | 27.10.2011 | 06:08 | 07:37 | 13:02 | 15:22 | 17:16 | 18:44 |
| Җомга | 28.10.2011 | 06:10 | 07:40 | 13:02 | 15:20 | 17:13 | 18:42 |

*Мәгълүматлар muslem.ru сайтыннан алынды*

# Мөфти АКШның Дәүләт сәркатибе ярдәмчесе белән очрашты



*Майкл ПОЗНЕР*

***14 октябрь көнне "Кол Шәриф" мәчетендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз АКШның демократия, кеше хокуклары һәм хезмәт буенча Дәүләт сәркатибе ярдәмчесе Майкл Познер белән очрашты.***

Татарстан мөфтие шәһәребез кунагына мәчет салыну тарихын бәян итте, шулай ук аны Татарстандагы дини хәл-әхвәл белән таныштырды. И.Фәиз шулай ук Диния нәзарәте структурасы, аның эшчәнлеге, төрле конфессиягә караган кешеләр арасындагы толерантлык мөнәсәбәтләре, хәнәфи мәзһәбе үзенчәлекләре һәм экстремизмга юл куймау юллары хакында сүз алып барды. Очрашу ахырында М.Познер Илдус хәзрәткә рәхмәтен белдерде.

**DUMRT.RU**

# Мөселман яшьләре тарихчы Фәйзелхак Ислаев белән очрашты

**(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)**

Бәлки урта гасырларда "урта" сүзен "урда" дип әйткәннәрдер", - дип белдерде галим.

### "Яшьләргә фикерләү җитми"

Очрашу ахырында Ф.Ислаев мөселман яшьләрен Коръәнне генә түгел, чит телләрне дә өйрәнергә чакырды. Үзе инглиз телен белмәү сәбәпле, галимнәр белән аралашканда кыенлыклар туу мисалын да китерде.

– Иң беренче чиратта, туган телеңне белергә, башка милләт вәкилләре исә Татарстанда яшәгәч, татар телен дә өйрәнергә тиеш. Тел белми торып, халыкны аңлап булмый. Тарих, социология, фәлсәфә фәннәрен укыгыз. Әмма укырга гына түгел, уйланырга да кирәк. Кызганыч, хәзерге яшьләр уйларга яратмый. Алар карый гына. Интернетны күзәтеп барырга өйрәнгәннәр, ләкин фикерләүләре җитеп бетми. Фикерләү сәләте китап укыганда, уйланганда, укыганда, язгалап барганда туа, – диде Ф.Ислаев.

Яшьләр очрашудан канәгать калды. Кунакка "Алтын урта"ның проектлар мәктәбеннән соң дөнья күргән брошюраны бүләк иттеләр, киләчәктә дә элемтәдә торырга, тарихи кичәләр үткәрергә килештеләр.

**Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА**
**Автор фотолары**

# Сабыр иткән – морадына җиткән

***Сөләйман пәйгамбәр заманында гарәпләрдән берәү, бер сандугачның авазына гашыйк булып, аны сайратыр өчен сатып алды. Бу сандугач гарәп кулында берничә көн сайрады. Аннары сайрамас булды. Гарәп әлеге кошны Сөләйман пәйгамбәр янына алып барды, чөнки ул кошлар телен белә иде.***

Гарәп әйтте:

– Бу кошны сайратыр өчен алган идем, берничә көн сайрады да тынып калды. Ни өчен сайрамый башлады икән? – диде.

Ул Сөләйман пәйгамбәрдән: "Сандугачтан сора әле", – дип үтенде.

Сөләйман сандугачтан: "Ни өчен тынып калдың?" – дип сорады.

Кош Сөләйман пәйгамбәргә әйтте:

– Баштагы сайравым шуның өчен: сөйгәнемне искә алып елар идем. Инде һавадан кошлар очып килеп, мине тәрәзәдән сөйгәнем күрде, миңа күп нәсихәтләр әйтте: "Бу кадәр елама, Аллаһ теләсә, бер кавышырбыз", – диде. Шуннан соң тынычланып калдым – җавап кайтарды.

Сөләйман пәйгамбәр сандугачның сүзен иясенә белдерде. Сөләйман пәйгамбәр кошны сатып алырга теләде, иясе сатты. Сөләйман сандугачны алганнан соң, азат итте, ирекккә чыгарды.

Бу хикәяттән гыйбрәт мәгълүм булды: һәртөрле авырлыкларда сабырлык иң яхшысыдыр.

**"Гыйбрәтле хикәятләр" китабыннан алынды**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №10 (107) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 дānә. **Заказ:** Е-510

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 20 октябрь, 17.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**